**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

| **«Раслыйм»**<br>Директор:<br>________Шәрәфетдинов Р.Г.<br><br>Боерык №<br>«28» август 2014 ел. | **«Килешенде»**<br>Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары:<br>____________Козлова Н.В.<br><br>«28» август 2014 нче ел. | **«Килешенде»**<br>Методик берләшмә җитәкчесе:<br>________Шәрәфетдинова Г.Ф<br><br>Беркетмә № __1_<br>«25» август 2014 ел. |
|---|---|---|

**7 нче “А” сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**
**(татар төркеме)**
Төзүче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрәфетдинова Гүзәл Фәсхетдин кызы

Педогогик киңәшмә
утырышында каралды.
Боерык № 1

2014-2015 нче уку елы

**Татар әдәбиятыннан эш программасы**
**7 нче сыйныф**
**(70сәг)**

***Аңлатма язуы***

***Эш программасы статусы.***
<u>Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:</u>

1 . “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы

2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы

3. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (№794 от 25.10.2013)

4. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен), 1- 11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010).
5. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.(Методик тәкъдимнәр)

6.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының МБГБУ“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең уку планына(Уку планы буенча боерык №179 1нче сентябрь 2014 нче ел)

7. Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланып тәкъдим ителгән татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләренең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен)/Ф.М.Мусин, Ә.М.Закирҗанов И.Г.Гыйләҗев, Р.С.Шәвәлиева, –Казан: “Мәгариф”, 2011)

Программа нигезенә Россия, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды, “Рус телендә урта (тулы ) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на нигезләнеп төзелде.

***Эш программасы структурасы***.
Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***
Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Структурасы – теория ярдәме белән, әдәби әсәрләргә анализ ясап, эчтәлек табу. Белем компонентлары өчәү: **теория**, өйрәнелә торган **объект** һәм алар арасындагы **бәйләнеш – анализ** гамәле.
Татар әдәбиятын укытуның **максатлары:**
матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү;
дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай булган шәхес **тәрбияләү**;
әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны, китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны, сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗын; укучыларның телдән һәм язма сөйләмен **үстерү**;
әдәбият белеменең нигез төшенчәләренә һәм әдәбият тарихының төп факторларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау; әсәрләрдәге конкрет-тарихи һәм гомумкешелек эчтәлекне аерып ала белү; телдән һәм язма чыгышларда әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалана белү **күнекмәләре булдыру.**

Укыту планында 7 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Планны " Рус телендә урта (тулы ) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы"на нигезләнеп төзелде. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова, Казан: Мәгариф, 2010) нигезләнеп төзедем. Программада 68 сәгать каралган, мәктәпнең укыту планы буенча 70 сәгать: язучы иҗаты – 52 сәгать. Класстан тыш уку – 6 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 12сәгать

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Язучы иҗатына анализ<br>Габдулла Тукай | 5 | |
| 2 | Байназар Әлменов. | 1 | Тормыш юлы. Иҗаты. "Исемдә калганна"әсәрен өйрәнү. "Шүрәле" поэмасы, "Туган авылым", "Кичке азан", "Татар яшьләре" шигырьләренә анализ. |
| 3 | Заһидулла Яруллин | 1 | Рәссам иҗаты турында белешмә. Әсәрләре хакында фикер алышу. |
| 4 | Фәрит Яруллин | 2 | Композитор иҗаты турында белешмә |
| 5 | Фатих Әмирхан | 2 | Композитор иҗаты турында белешмә |
| 6 | Мәҗит Гафури | 3 | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. "Март каһарманы" хикәясен өйрәнү. |
| 7 | Галимҗан Ибраһимов | 5 | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә."Татар байрагы" шигырен, "Сарыкны кем ашаган?" "Ике чебен"мәсәлен өйрәнү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Гадел Кутуй | 5 | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “Алмачуар” хикәясен өйрәнү, анализлау. |
| 9 | Хәсән Туфан | 4 | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “Сагыну” нәсерен, “Рөстәм маҗаралары” повестен өйрәнү, анализлау. |
| 10 | Зифа Басыйрова | 1 | Тормыш юлы. Иҗаты. Шигырьләренә анализ: “Киек казлар”, “Талатлы син, кеше туганым” |
| 11 | Роза Хафизова | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. Татар җыр сәнгатенә керткән өлеше. |
| 12 | Ибраһим Салахов | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “ Кашкарыйлар озын гомерле” әсәрен өйрәнү, анализлау |
| 13 | Зыя Мансур | 2 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Колыма хикәяләре” романыннан өзеккә анализ ясау |
| 14 | Әмирхан Еники | 5 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Таңсылу әкияте2 әсәрен өйрәнү, анализ. |
| 15 | Рафаил Төхфәтуллин | 2 | Тормыш юлы. Иҗаты.”Кем җырлады?”, “Матурлык” әсәрләрен өйрәнү, анализ |
| 16 | Гөлшат Зөйнәшева | 2 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Балам көлүе” нәсерен өйрәнү |
| 17 | Тәүфикъ Әйди | 2 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Туган җирем - Татарстан” шигырен өйрәнү |
| 18 | Класстан тыш уку | 6 | “Йөртә безне язмышлар” сәяхәтнамәсе белән танышу. |
| | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 12 | |
| | Нәүрүз бәйрәме | 1 | |

***Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:***

сүз сәнгатенең образлы табигате;
өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеге;
классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторлары;
өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләр;
әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясын ачыклау;
геройларга характеристика бирү;
сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
автор позициясен ачыклау;
укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;

кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерне белдерү;
укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилли белү;
укыган әсәрләргә бәяләмә (отзыв) язу;
татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле белешмә әдәбият, вакытлы матбуга, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

## Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дәрес тибы | Дәрестә кулланылган эш төрләре | Контроль төре | Үзләштерергә яки камилләштерергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Өй эше | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | План | Факт |
| 1 | Габдулла Тукай | 1 | Яңа материалны өйрәнү дәресе | | | Шагыйрь иҗаты турында белешмә | Шагыйрьнең балачак юлларын схемада бирергә | 04.09 | |
| 2 | Исемдә калганнар I-II бүлекләр | 1 | Уку дәресе | | | Әсәр белән танышу. Шагыйрь балачагының бирелеше | I-II бүлекләргә исем бирергә, кыскача план төзергә | 06.09 | |
| 3 | Исемдә калганнар III-IV бүлекләр | 1 | Дәрес-әңгәмә | схема | | Әсәрне өйрәнүне дәвам итү. Габдулланың Кырлайдагы тормышы | III-IV бүлекләргә исем бирергә, 18 нче бит сораулар | 11.09 | |
| 4 | “Шүрәле” поэмасы | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Поэма белән танышу. Әсәрдә туган якка мәхәббәтнең чагылы -шы, табигатьнең сурәтләнүе | Эчтәлеген хикәя рәвешендә сөйләргә | 13.09 | |
| 5 | “Кичке азан.”, “Татар яшьләре” шигырьләре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Шигырь белән танышу. Милләтне берләшергә чакыру мәсьәләләре | Йөгерек укырга өйрәнергә | 18.09 | |
| 6 | Байназар Әлменов “Исемдә калганнар “ иллюстрациясе | 1 | Бсү | әңгәмә | Сочинение | Рәссам иҗаты турында белешмә. Әсәрләре хакында фикер алышу | Язып бетерергә | 20.09 | |
| 7 | Заһидулла Яруллин | 1 | Яңа | | | Композитор иҗаты турында | 28-29 битләргә 6 | 25.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | материал -ны өйрәнү | | | белешмә | сорау хәзерләргә | | |
| 8 | Фәрит Яруллин | 1 | Яңа материал -ны өйрәнү дәресе | | | Композитор иҗаты турында белешмә. Балет турында төшенчә. “Шүрәле” балеты белән танышу. Әнисе Нәгыймә апа -Хәерби кызы турында мәгълүмат бирү | Ф Яруллин иҗаты буенча диалогка хәзерләнергә. Либ -ретто, сценарий, сюжет терминна -рын ятларга | 26.09 | |
| 9 | “Шүрәле балеты” Б.с.ү.Балет карагач | 2 | Дәрес -әңгәмә Бсү | Интернет-ресурс “Шүрәле ” балеты | | “Шүрәле “балеты белән танышу.<br>Видеоязмада балет карау | Балет карагач туган тәэсирләр. Язма эш | 02.10<br>03.10 | |
| 10 | Фатих Әмирхан | 1 | Яңа материал -ны өйрәнү дәресе | | | Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. | 36-37 укырга. “Март каһарманы” - I бүлек | 09.10 | |
| 11 | “Март каһарманы” хикәясе | 1 | Уку дәресе (кычкырып уку, күңелдән уку, аңлатма лы уку) | | | Хикәянең эчтәлеге өстендә эшләү. Темасын, проблемасын ачу. Рево- люция тәэсирендә барлыкка кил- гән каһарман исеме астында яше- ренгән кешеләрне тәнкыйтьләү | Бүлекләргә исем бирергә, сорауларга җавап хәзерләргә | 10.10 | |
| 12 | Каһарман Мулланур Вахитов | 1 | Бсү | | | Каһарманның тормыш юлы, ба-тырлыгы турында белешмә. | Казан шәһәрендәге тарихи һәйкәлләр | 16.10 | |
| 13 | Мәҗит Гафури иҗаты | 1 | Яңа материал -ны өйрәнү дәресе | | | Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. | Тезислар форма -сында план төзеп, шул план буенча сөйләргә | 17.10 | |
| 14 | “Татар байрагы” шигыре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Шигырьне сәнгатьле итеп уку күнекмәләре бирү. Темасын билгеләү. Шигырь аша милләт язмышын тасвирлау | Шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләргә | 23.10 | |
| 15 | “Сарыкны кем | 1 | Сәнгатьле | | | Мәсәл турында төшенчә. | Образларга | 24.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ашаган?” “Ике чебен” мәсәле | | уку дәресе | | | Мәсәл- ләрнең жанр буларак үзенчәлеге. Мәсәлне рольләргә бүлеп уку. | характеристика | | |
| 16 | Галимҗан Ибраһимов иҗаты. | 1 | Яңа материал өйрәнү дәресе | | | Тормыш юлы , күпкырлы эшчәнлеге | “Алмачуар” хикәясе I-V бүлек | 30.10 | |
| 17 | “Алмачуар” хикәясе V-VII бүлекләр | 1 | Уку дәресе (кычкырып уку, күңелдән уку, аңлатмалы уку) | | | Хикәяне аңлап уку.Нәсер төшенчәсе. Атка булган мәхәббәтнең сурәтләнүе | Бүлекләргә исем бирергә. VIII-X бүлекләр укырга | 31.10 | |
| 18 | “Алмачуар” хикәясе XI-XV бүлекләр | 1 | Дәрес-әңгәмә | | | Әсәр өйрәнүне дәвам итү, тулы- сынча эчтәлеген сөйләтү. Закир тормышындагы үзгәрешләр. Әсәр дә гореф-гадәтләрнең бирелеше | XVI-XVIII бүлекләр укырга | 13.11 | |
| 19 | “Алмачуар” хикәясенең сюжет композициясе, конфликт үзенчәлеге | 1 | Дәрес - әңгәмә | | | Хикәянең эчтәлеге өстендә эшләү. Темасын, проблемасын ачу. Конфликтны табу | Кешеләргә хас бул -ган яхшы сыйфат- ларны язып кил- ергә. Бер-ике об -разга характерис- тика язып килергә | 14.11 | |
| 20 | “Алмачуар” хикәясендә образлар системасы | 1 | Анализлау дәресе, образлар аша анализлау | | 10 мин тест | Өйдә укып килгән әсәр өстендә эшләү: эчтәлеген, күтәрелгән проб -лемаларны ачыклау, геройларның эчке портретларын төзү, характе-ристика бирү. Кешене кимсетү, рәнҗетү - түбәнлек, мәрхәмәтсез- лек икәнлекне ачыклау. Алмачу -арның үлеме тудырган хисләр. Хикәядә тормыш тәҗрибәсе һәм яшьлек, вөҗдан газабы һәм | Сочинениегә материал туплау | 20.11 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | саф- лык төшенчәләре. | | | |
| 21 | Сочинение “Алмачуар” хикәясендә мине уйландырган образ | 1 | Бсү | | | | Сочинение язып бетерергә | 21.11 | |
| 22 | Табигать балалары | 1 | Кту | | | Эчтәлек өстендә эшләү. Темасын, проблемасын билгеләү. Геройлар- га характеристика бирү. Революциягә кадәр авыл тормышының , кеше психологиясенең бирелеше | Төп геройга характеристика | 27.11 | |
| 23 | Гадел Кутуйның тормыш юлы, иҗаты | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә | 70-71 укырга, сөйләргә | 28.11 | |
| 24 | “Сагыну” нәсере | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Нәсер турында төшенчә. Нәсер бе -лән танышу. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә Туган ил образы | Өзекне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнергә | 04.12 | |
| 25 | “Рөстәм маҗаралары” повесте | 1 | Уку дәресе | | | Повесть белән танышу. Әсәрдәге фантастик вакыйгалар, чынлык дөньясы белән хыял дөньясының яраштырылып бирелүе | Абага чәчәгенең рәсемен ясарга. Энциклопедиядән мәгълүмат язарга | 05.12 | |
| 26 | “Рөстәм маҗаралары” повесте | 1 | Уку-анализ ясау | | | Эчтәлек өстендә эшләү | Эчтәлекне сөйләргә | 11.12 | |
| 27 | “Рөстәм маҗаралары” повесте | 1 | Йомгаклау дәресе | | | Эчтәлек өстендә эшләү. Темасын, проблемасын билгеләү.Төп герой- га характеристика. | КТУ га хәзерләнергә | 12.12 | |
| 28 | Г.Кутуй “Рәссам” | 1 | Кту | | | | Миниатюр сочинение. Абага чәчәге ашасам… | 18.12 | |
| 29 | Хәсән Туфан | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | Китап күргәзмәсе | | Шагыйрь турында белешмә. Әдип -нең 20-30 еллар һәм соңгы дәвер иҗатына күзәтү | Шагыйрь турында диалогик | 19.12 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | сөйләмгә хәзерләнергә | | |
| 30 | Х.Туфан “Киек казлар” шигыре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Шигырьне сәнгатьле итеп уку, язылу тарихы турында белешмә бирү. Күчерелмә мәгънә. Шигырьгә тулы анализ | Шигырьне ятларга | 25.12 | |
| 31 | Х.Туфан “Талантлы син, кеше туганым” шигыре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Шигырьне сәнгатьле итеп уку, язылу тарихы турында белешмә бирү. Шигырьгә тулы анализ | “Шигырьләрдә шагыйрь шәхесе” темасына сөйлә - шергә әзерләнергә | 26.12 | |
| 32 | “Шигырьләрдә шагыйрь хисе” | 1 | Бсү | | | | Үзең яраткан бер шигырьгә анализ | 15.01 | |
| 33 | Газиз Кашапов “Киек каз Юлы” | 1 | Класстан тыш уку дәресе | Истәлекләр | | Язучы турында белешмә. “Киек каз юлы” әсәре белән танышу | Язучы турында сөйләргә | 16.01 | |
| 34 | Г.Гобәй.Ләйсән яңгыр | 1 | Класстан тыш уку дәресе | | | Әсәр- дәге проблема, тема. Төп геройга характеристика. | Укып бетерергә | 22.01 | |
| 35 | Туган җир | 1 | Бсү | | | Туган җир төшенчәсен аңлау | “Туган җирем табигате”- сочинен | 23.01 | |
| 36 | Зифа Басыйрова | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | Интернет ресурс | | Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Аның татар җыр сәнгатенә керткән өлеше | Бөгелмә районыннан чыккан берәр җыр чы турында язарга | 29.01 | |
| 37 | Роза Хафизова Кашкарыйлар озын гомерле” әсәре | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Язучының яшь буынны тәрбияләүгә керткән өлешен билгеләү | Конспектларга, сөйләргә | 30.01 | |
| 38 | “Кашкарыйлар озын гомерле” әсәре | 1 | Уку дәресе | | | Әсәр белән танышу. Яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе, хезмәт сөючән балалар образлары тудырылуы | Сорауларга һәм биремнәргә телдән хәзерләнергә | 05.02 | |
| 39 | “Кашкарыйлар озын | 1 | Уку дәресе | | | Хыялый ситуацияләрне | Сораулар буенча | 06.02 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомерле” | | | | | анализлау | әзерләнергә | | |
| 40 | Әсәрдә образлар системасы | 1 | Уку-анализ, образлар аша анализлау | | | Төп геройларга характеристика. Әсәр белән бәйләп җәйге лагерьда ял итү истәлекләре белән уртаклашу | Колыма хикәяләре укырга | 12.02 | |
| 41 | Ибраһим Салахов | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә | Колыма хикәяләре укырга | 13.02 | |
| 42-43 | “Колыма хикәяләре” романы | 2 | Уку дәресе, анализ ясау | | | Әсәрдә Сталинизм заманында нахакка ябылган татар зыялыларының фаҗигале язмышының бирелеше | Әсәрне тулысы белән укып бетерергә | 19.02 20.02 | |
| 44 | “Колыма” хикәяләре | 1 | Кту | | | Сайлап алынган бүлекләрне уку | “Ана –бөек исем”.Сочинение га материал туплау | 26.02 | |
| 45 | Ана – бөек исем | 1 | Бсү | | Сочинени е | Чегән хатыны образы аша аналар образын ачау. Сочинение-фикерләү | Язып бетерергә | 27.02 | |
| 46 | Зыя Мансур | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә | Иҗаты буенча диалогка хәзерлә | 05.03 | |
| 47 | “Таңсылу” әкияте | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Таңсылуның язмышына иптәш кызларының карашы, әсәрнең идеясе. Идея турында төшенчә. | Эчтәлеген хикәя рәвешендә сөйләргә | 06.03 | |
| 48 | Әмирхан Еники “Кем җырлады?” хикәясе | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Язучы турында белешмә | Тормышы, иҗаты турында сөйләргә | 12.03 | |
| 49 | Җырның сихри көче | 1 | Бсү | | | Татар җырының ялы егеткә тәэ -сире “Кем җырлады” иллюстра -циясе буенча әңгәмә кору | Үз фикереңне язып килергә | 13.03 | |
| 50 | “Матурлык” хикәясе | 1 | Аңлап уку дәресе | Аудио язма | | Әсәрне аңлап уку. Җанлы образ -ларның бирелеше, автор тарафын- нан аларның эчке дөньясының күр -кәм, матур | Укып бетерергә. Сорау һәм биремнәр | 19.03 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | сыйфатларының тасвирлануы | | | |
| 51 | “Матурлык” хикәясе | 1 | Уку-анализ ясау | | | Бәдретдин белән әнисенең эчкер -сез мөлаем мөнәсәбәте. Табигать матурлыгы, бит-йөз матурлыгы, кеше күңеле матурлыгы | БСҮ хәзерләнергә | 20.03 | |
| 52 | Кешенең матурлыгы нәрсәдә? | 1 | Бсү | | 10 мин тест | Ә.Еники иҗаты буенча тест | КТУ га хәзерләнергә | 21.03 | |
| 53 | Рафаил Төхфәтуллин | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | | | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә | Хронологик таблица төзергә | 02.04 | |
| 54 | “Балам көлүе” нәсере | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | | | Әсәрдә ата-ана һәм бала хисләренең чагылышы. Язучының әйтергә теләгән фикере | Язма эшкә хәзерләнергә | 03.04 | |
| 55 | Аерылышулар булмаса, шатлыклы очрашулар да булмас иде | 1 | Бсү | | Сочинение | Сочинение - фикерләү | Нәүрүз бәйрәме турында белешмә материал | 09.04 | |
| 56 | Нәүрүз бәйрәме | 1 | Дәрес-әңгәмә | Мәктәптә Нәүрүз бәйрәмен үткәрү | | Текстны рольләргә бүлеп уку Татар халык уеннарын уйнау | Яратып укыган әсәрең турында язарга әзерлән | 10.04 | |
| 57 | Тукай көннәре .Г.Тукайга багышланган шигырьләр. Мәсәлләр | 1 | Дәрес-экскурсия | | | | | 16.04 | |
| 58 | Сәләт-сәләтлеләрне җыя. | 1 | Дәрес-реклама | | | | | 17.04 | |
| 59 | Ялкын журналы бездә кунакта | 1 | Дәрес -презентация | | | | | 23.04 | |
| 60 | Гөлшат Зәйнашева . Иҗаты һәм тормыш юлы | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырлар тыңлау | | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Туган җирем-Татарстан” шигыре белән танышу | Шигырь яттан | 24.04 | |
| 61 | Гөлшат Зәйнашева. | 1 | Сәнгатьле | | | Сайлап уку | 1 шигырен | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Шигырьләрен сәнгатьле уку дәресе | | уку дәресе | | | | сәнгатьле итеп укырга | 01.05 | |
| 62 | Ватаным-Татарстан | 1 | Бсү | Дәрес-сәяхәт | | Дәрес 161 нче биттә бирелгән сорауларга нигезләнеп үткәрелә | Аксубай районы Сөнчәле авылының истәлекле урыннар (материал туплый башларга) | 07.05 | |
| 63 | Тәүфикъ Әйди | 1 | Яңа теманы өйрәнү дәресе | истәлекләр | | ”Йөртә безне язмышлар” сәяхәтнамәсе белән танышу | Бсү гә хәзерләнергә | 08.05 | |
| 64 | Чит илләрдәге милләттәшләребез | 1 | Бсү | Презентациялар | | Матбугат битләреннән чит илдә яшәүче милләттәшләребез язмышы белән танышу | Материал туплауны дәвам итәргә | 14.05 | |
| 65 | Ф. Шәфигуллин әсәрләре | 1 | Кту | Китап күргәзмәсе | | Иҗаты һәм тормыш юлы белән танышу | Рефератларны алып килергә | 15.05 | |
| 67 | Нәүрүз бәйрәме | 1 | Бсү | Дәрес - сәяхәт | | | | 21.05 | |
| 68 | Уку елында яратып укыган әсәрем. Татар китабы презентациясе | 1 | Б.с.ү. | Татар китабы рекламасы | | Сочинение - хикәяләү | Зачетка хәзерләнергә | 22.05 | |
| 69 | “Туган авылым Сөнчәлем” | 1 | Бсү | | | Авылның истәлекле урыннары турында сөйләү. | | 28.05 | |
| 70 | Йомгаклау дәресе | 1 | Йомгаклау дәресе | Зачет сорау -ларына җавап бирү | Зачет | 8 нче класска әсәрләр исемлеге | | 29.05 | |

**Татар әдәбиятыннан сочинениене бәяләү критериясе**

**Сочинениене бәяләү**

| Мәктәп тибы Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
| --- | --- | --- |
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хата. |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысыңча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

## Укыту – методик комплекты

1. “ Рус телендә урта (тулы ) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова, Казан: Мәгариф, 2010) (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)
2. .Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.(Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М.,Хаков В.Х., Г.Г., Хәмидуллина Э.Х.Казан,**.)**
3. **Дәреслек.** Ф.М.Мусин, И.Г.Гыйлаҗев, Р.С.Шәвәлиев. Татар әдәбияты. 7 сыйныф, 2010.
4. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина,М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.-Казан:Мәгариф,2005.
5. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-6нчы сыйныфларында эшләүче укытучылар өчен кулланма/Я.Х.Абдрәхимова.-Казан: Мәгариф,2007
6. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. /Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2000